


*/Мәктәп тормышы/*

## *Студентлар белән очрашу*

26 гыйнвар көнне безнең мәктәпне тәмамлаган укучылар – бүгенге студентлар белән очрашу үтте. Алар студент тормышы турында, дәресләр, яшәү шартлары хакында, беренче көннәрдә булган дулкынланулары, мәктәпне сагынулары турында сөйләделәр. Чыгарылыш сыйныф укучыларына алга таба нинди һөнәр сайлау буенча үзләренең киңәшләрен дә бирделәр. Билгеле инде, чыгарылыш сыйныф укучылары аларга үзләрен кызыксындырган сорауларны яудырдылар. Барысы да кызыксындыра булып чыкты аларны. Уку авырмы, буш вакытлар ничек үтә? Имтиханнарны нинди формада бирүләре хакында, дәресләрнең нинди формаларда үтүләре турында сораштылар. Ул гына да түгел, "Якынча студентка атнага ничә сум акча кирәк, кимсетмиләрме, Казанда адашып калган очраклары булмадымы?" – кебек сорауларга да җаваплар ишеттеләр укучылар. Тиздән үзләре дә олы тормыш юлына басачак укучыларны студент тормышы бик кызыксындыра икән.

***Алсу Сафиуллина, XIсыйныф җитәкчесе***

---

## *Сугыш хатирәләрен яңартып*




27 гыйнвар – безнең ил тарихында үзенчәлекле дата. 1945нче елны бу көнне Кызыл Армия иң зур "үлем лагерен" – Аушвиц-Биркенауны (Освенцимны) азат итә. Шул сәбәпле бу көн Холокост корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге истәлекле дата хөрмәтенә мәктәптә «История в деталях» исемле тарихи квест үткәрелде. Анда, укучылар ике командага бүленеп, мәктәп буенча алдан эленгән постерлардан сорауларга җаваплар эзләп йөрделәр. Постерларда исә Холокост турында әһәмиятле, ләкин ачык булмаган мәгълүматлар иде.

1944 елның 27 гыйнварында Ленинград шәһәре Германия гаскәрләре блокадасыннан тулысынча азат ителә. Быел бу тарихи вакыйгага 80 ел тулды. Безнең мәктәптә V-VIII сыйныфлар өчен Ленинград блокадасына багышланган кинолекторий үткәрелде. Анда укучылар "Ленинград блокадасы балалар күзлегеннән" кинокартинасын карап, ул чорда булып үткән вакыйгаларны тагын бер кат искә төшерделәр. Фильмны караганнан соң блокада вакыйгалары турында ачык диалог форматында бергәләп фикер алыштылар. Динә апа уздырган чаралар безгә ошый, эшендә уңышлар теләп калабыз.

***Самат Гафиятуллин, X сыйныф укучысы***

---

*/Күңелле тәнәфес/*

## *ВИКТОРИНА*



1. 1895нче елда туган татар шагыйре.
2. Тукайның туган авылы.
3. Татар телендә кеше исемнәре сүзлегенең авторы.
4. 2023 нче елда Тукай бүләгенә лаек булган язучы.
5. XIX йөздә университетта рус теле укыткан татар кешесе.
6. Тукай яшәгән кунакханәнең исеме.
8. Болгар дәүләтендәге шәһәр.
9. Казан губернасында туган рус шагыйре.
10. Сөембикәнең улының исеме.
11. Казан университетында эшләгән каллиграф.
12. 1755нче елгы татар-башкорт явының рухи җитәкчесе Батыршаның исеме.
13. Медицина фәненең элеккеге атамасы.
14. Татарның беренче дирижеры.
15. Ф.Әмирхан чыгарган газета.
16. Беренче театр операсы.
17. Тукай язышкан сатирик журнал.
18. XX гасыр башында Франциядә укыткан татар галиме.

**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**
**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**
**<u>Редколлегия әгъзалары:</u> Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин**

# *Мәктәп хәбәрчесе*

**№1**
**(№52)**
**гыйнвар**
**2024 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газете***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**




*/Мәктәп тормышы/*

## *Мәктәптә яңа вазифа*

Бу елның уникенче гыйнварыннан алып мин мәктәпкә тәрбия буенча директор киңәшчесе булып эшкә кердем. Ләкин бу вазифа минем өчен генә түгел, башкалар өчен дә яңа булып чыкты. Шуңа күрә монда тәрбия буенча директор киңәшчесенең нинди эш башкаруы, нинди бурычлары булуы турында сөйләп китәргә уйладым. Киңәшченең төп максаты – баларның рухи, әхлакый кыйммәтләрне дөрес формалаштыру һәм дөрес социаль юнәлешләр билгеләү юлы белән аларның шәхесен үстерүгә юнәлтелгән бурычларны хәл итү. Гади итеп әйткәндә, белгеч балаларга аларның мәдәни диапазонын киңәйтә торган актив ял белән шөгыльләнергә ярдәм итәчәк.

Тәрбия эше буенча урынбасар белән киңәшче охшаш урын алып торсалар да, аларның эшләре бер түгел. Урынбасар – беренче чиратта идарәче, ягъни административ буын вәкиле. Еш кына мондый хезмәткәрләрнең укучылар белән турыдан-туры элемтәгә керү өчен вакытлары калмый. Киңәшче – нәкъ менә "кырда" эшләячәк белгеч, ягъни мәктәп укучылары белән турыдан-туры элемтәдә булачак.

Тәрбия буенча директор киңәшчесе эшчәнлегенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- төрле балаларны оешмалары белән эш алып бару;
- мәдәният, спорт оешмаларын, социаль партнерларны ата-аналар һәм укучылар белән эшләргә җәлеп итү;
- ата-аналарга яисә башка законлы вәкилләргә методик һәм консультатив ярдәм күрсәтү;
- укучылар үзидарәсен башлап җибәрү һәм аңа ярдәм итү;
- балалар иҗтимагый оешмаларының, берләшмәләрнең үсешенә һәм эшчәнлегенә ярдәм итү, аларның эшчәнлек программаларын эшләүдә булышу;
- укучыларның инициативасын, аларның яшь мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын исәпкә алып, ярдәм күрсәтү;
- балаларның коллектив-иҗади эшчәнлеген оештыру, мөстәкыйльлекләрен хуплау (Моңа буш вакытларын файдалы үткәрергә ярдәм итә торган социаль әһәмиятле эшләр дә керә (волонтерлык, флешмоблар, социаль акцияләр һ.б.));
- укучыларны түгәрәкләргә, секцияләргә, клубларга, студияләргә һәм башка берләшмәләргә җәлеп итү;
- мәктәптә уздырыла торган төрле чараларны үткәрүдә катнашу;
- бердәм гамәл көннәрендә (дни единых действий) үткәрелергә тиешле чараларны оештыру һ.б.

Соңгы вакытта укучыларга оештырган чараларның күбесе бердәм гамәл көннәре хөрмәтенә иделәр. Ул көннәр Бөек Ватан сугышының башка вакыйгаларына, студентлар көненә, туган тел көненә багышландылар. 26 гыйнвар көнне уздырылган квест холокост корбаннарын искә алуга багышланган иде. Анда укучылар ике командага бүленеп, мәктәп буенча алдан эленгән постерлардан сорауларга җаваплар эзләп йөрделәр.

Шулай ук укучылар үзидәресен оештыруга беренче адымнар ясалды. Балалар үз инициативасын күрсәтә башласыннар өчен бу бик мөһим. Үзидарә мәктәп һәм балаларның үзләре өчен файдалы булыр дигән өметтә калабыз Ахырдан укучыларга, укытучыларга, администрациягә күрсәткән ярдәмнәре өчен зур рәхмәт әйтәсем килә. Бу вазифа минем өчен яңа, һәм сезнең ярдәмегез булмаса, мин башкарырга тиешле эшләрне эшли алмас идем. Киләчәктә бер-беребезгә ярдәм күрсәтеп, аңлашып эшли алырбыз дип өметләнәм.

***Динә Насыйрова, тәрбия эшләре буенча киңәшче***

---

*/Котлыйбыз!/*




Гыйнвар аенда дөньяга килгән дусларыбыз (III сыйныф)**Хәйруллин Мансурны** (I сыйныф), **Галиәскәрова Айшә** белән**Залиев Илфирны**(III сыйныфлар), **Закирова Ләйсәнне** (VI сыйныф) туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында зур уңышларга ирешүләрен телибез.

Мәктәп хезмәттәшләреннән математика укытучысы **Зарипов Фәнил абыйны**, физика-информатика укытучысы **Хәснуллин Фәнис абыйны** гомер бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Аларга тормыш иминлеге, сәламәтлек, озын гомер теләп калабыз.

*/Рәсми хәбәрләр/*

## *“Минем мәктәп” (“Моя школа”) – яңа электрон көндәлек*

Уку елының беренче яртысы бетеп, яңа ел бәйрәмнәрен каршыларга әзерләнгәндә, мәктәпләрдә яңа электрон журналга күчү башланды. Яңалыкны авыр кабул итсәк тә, тиз арада төшенеп эшләп тә куйдык. Бу яңартылган дәүләт мәгълүмат системасына Россия дәүләт хезмәте порталы аша теркәлү узып керү кирәк. Моны порталда шәхси мәгълүматларны саклау куркынычсызлыгы максимаь рәвештә саклану белән аңлаталар. 14 яшьтән өлкәнрәк булган бала үзе дәүләт хезмәте порталына теркәлә. Моның өчен беркая да барырга, йөрергә кирәкми, барысы да онлайн эшләнә. Балаларга, әти-әниләргә мәктәптә 22нче гыйнвардан электрон көндәлеккә керү өчен логин һәм пароль бирелде. Ул һәр баланыкы шәхси. Шуннан соң әти-әниләр, укучылар теркәлү узды. Элекке көндәлекләрдә билге төзәтү буенча кыенлыклар бар иде. Яңасында анысы да хәл ителгән. Укучы 21 көн эчендә билгесен төзәтергә хокуклы. Кәгазь көндәлекләр, укытучы журналы бетте. Укучы үзе теләсә элеккеге кебек көндәлек алып бара ала. Әмма анда билге куелмаячак. Бар укучыларга да билге электрон көндәлекләрдә куела. Яңа электрон көндәлектә укытучы укучының өлгереше буенча ата-анага шәрехләмә дә калдыра ала.




Ә менә чыгарылыш сыйныф укучысының әти-әнисе аның шәхси мәгълүматларын күрсәтергә теләми икән, баласын аттестатсыз калдырырга да мөмкин. Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыру өчен укучы турындагы мәгълүматны дәүләт йомгаклау аттестациясенең федераль мәгариф системасына кертергә кирәк. Моны укытучылар башкара. Мәгълүмат булмыйча, укучы теркәлү узмаса, ул имтиханга кертелми. Димәк, аттестат урынына мәктәпне тәмамлавы турында белешмә генә алачак. «ТР электрон мәгариф» яңартылган дәүләт мәгълүмат системасында теркәлгән укучылар узган дәрес материаллары буенча белемнәрен дә ныгыта ала, имтиханга да әзерләнә ала. Ата-ана баласының билгеләреннән битәр, мәктәптә алган белем базасы буенча анализны, мәктәптәге активлыгын да карый ала. Укытучылар исә дәресләргә әзерләнә ала. Министр әйтүенчә, укытучылар һәм мәктәп администрациясе өчен 75 процентан артык мөмкинлекләр каралган.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

***/ Мәктәп тормышы/***

## *15нче гыйнвар – кышлаучы кошлар көне*



Быелгы гыйнвар аебыз, тасвирлап бетермәслек дәрәҗәдә карга бай булып килде. Көне-төне кар ява, урамнарда юллар югала. Хәтта мәктәпкә укырга килә алмаган көннәр дә булды. Кыш үзенең йомшак, мамыктай ак юрганы белән бар җирне каплап алды. Әйтерсең лә табигать шулай итеп бар терекленә ял итәргә өнди.

Кар катламының калын булуы кошлар өчен азык табуны нык кыенлаштыра. Әгәр без нәни дусларыбыз – кошлар турында онытсак, алар кышны ничек чыгар? Шуны истә тотып, балаларда кошларга карата экологик белемле мөнәсәбәт формалаштыруны дәвам итү максатыннан, 16 нчы гыйнвар көнне мәктәбебездә сыйныф сәгате үткәрелде. Башлангыч сыйныф балалары белән кышның кошлар тормышы өчен бик авыр ел фасылы булуы һәм төрле кошларның ничек итеп бу кыенлыкларны җиңеп чыгулары турында әңгәмә үткәрелде. Бу чара барышында кошларны танып белү уены үткәрелде. Балалар өчен бигрәк тә кошларның тавышларын тыңлау, аларны аеру, табышмакларга җавап табу мавыктыргыч булды. Укучылар кышларга безнең якларда калучы һәм җылы якка китүче күчмә кошлар турында белемнәрен ныгыттылар.

Сыйныф сәгатеннән соң балаларга өй эшләре бирелде. Алар җимлекләр ясап килергә тиеш иде. Кошларга җимлек ясаучы осталарыбыз: 1 нче сыйныфтан**Замалетдинов Фирдүс, Хәбибрахманова Асия, Хәйруллин Мансур,** 2 нче сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә, Хафизов Илфат,** 3 нче сыйныфтан **Галиәскәрова Айшә, Закиров Инсаф, Камалов Илнур, Сафиуллина Гөлсем,** 4 нче сыйныфтан **Мифтахов Рамазан, Хәфизов Ирек.** Менә шушы чаралар аркылы балаларыбыз тирә-юньгә битараф булмыйча, нәни дусларыбызны яратып, аларга карата мәрхәмәтлелек хисләре белән үсәләр.

***Сафия Хәбибрахманова, башлангыч сыйныфлар укытучысы***




***/Безгә кунак килде/***

## *Ак калфакның табылган чагы*

Каникул көннәрен бушка уткәрмәуне күздә тотып, мәктәбебезгә Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Нурхәмәтова Әлфия Рәшит кызын кунакка чакырдык. Әлфия апаның безгә килу максаты кызларыбызны калфак чигәргә өйрәтү иде.

Калфак – бик үзенчәлекле һәм татар халкы өчен генә хас булган хатын-кыз баш киеме. Әлфия апа иң баштан калфаклар төре һәм тарихы белән таныштырды. Аның килеп чыгышы ерак гасырларга барып тоташа. XVII – XVIII гасырларда безнең якларга килеп чыккан сәяхәтчеләрнең рәсемнәренә караганда, ул чорның хатын-кызларында өскә таба очлайтып ясалган каты баш киеме булган. Иң беренче калфаклар 1 м озынлыкта була, алар ак җептән бәйләнгән һәм өстендә чигелешләр белән бизәлеп эшләнгән. Калфакның иясе чәчләрен шунда яшерә торган булган. Заманалар узу белән калфаклар кечерәя бара. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына калфакларның үлчәме кечерәя, каты кырпулы хәтфә калфаклар, соңрак бәрхет калфаклар киң таралыш ала. Алар түгәрәкләп ясалган һәм чәчкә кадап кына куелган. Хатын-кызлар аны яулык яки ефәк шәл астыннан киеп йөргәннәр.

Ни өчен үзебезнең милли киемнәрне, милли бизәкләрне өйрәнергә тиеш? Чөнки үзебезнең тарихны, милли бизәкләребезне белмәсәк, бездә милли горурлык хисе дә калмаячак. Без башка кием әзли башлыйбыз, чит милләтләрнең киемен киябез, ә үзебезнекен онытабыз. “Кешегә иң беренче карагач, аның нинди милләттән булуын өстенә киган киеме әйтә, аннан соң гына теле“, – ди Әлфия апа.

Остазыбыз калфаклар төре һәм тарихы белән таныштырганнан соң, әкренләп кенә “тырнакалмалау” чигу ысулына күчте. “Калфакларымны “колак сыман” чигүе белән эшлим. Чәчәкләр аерым элементлардан җыела, ә аларның формасы колакка охшаган, шуңа “колак сыман” чигү дип атаганнар. Шушы әзерләгән чәчәкләрне калфакка беркетеп, бизәк ясыйм. Эшләр өчен бәрхет тукыма, капрон яки атлас тасма, сәйләннәр, төрле төймәләр кирәк. Бер калфакны ун көндә өлгертергә мөмкин. Тамбур һәм сәйләннәр белән дә чиккәнем булды. “Колак сыман” чигү онытылып бара, бу ысул белән эшләүчеләр аз. Ә ул бик матур һәм үзенчәлекле. Шуңа күрә бу чигү күбрәк кызыксындырды. Ул онытылмаска тиеш һәм киләсе буыннарга да барып җитсен иде” — ди калфак чигү остасы. Әлфия апа бу чигү ысулының барлык нечкәлекләре турында бик җентекләп сөйләде. Осталык дәресенә килгән укучыларыбыз беренче чәчәкләрен дә ясап карадылар. Кызларыбыз һәм апалар киләчәктә үзләренә калфак тегү нияте белән үлчәмнәр дә алып калдылар. Без исә киләчәктә кызларыбыз үзебезнең милли калфакларыбызны чигеп, киеп йөрерләр дигән өметтә калабыз.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***



***/Укучылар иҗаты/***

## *Кышның могҗизасы*

Быел кыш чып-чын кыш булды. Укытучылар сөйләвенчә–алар балачагындагы кыш. Көздән беренче карлар төшүгә туңдырып җибәрде дә, хуҗалыгын барлап, җиң сызганып эшенә тотынды. Карны бер кызганмыйча өем-өем яудырды да, бөтен тирә-якны аклыкка күмде. Берзаман ул гына да җитми башлады, Буран әфәнде өерелеп тонъяктан килеп керде. Авыл уртасына җиткәч, тирән итеп сулыш алды да, карларны туздырып-туздырып юлларга, өй нигезләренә китереп сылады. Өй түбәләренә дә бүрекләр кигертте. Бәлки ул безне туңмасыннар дип шулай эшлидер.

Җил белән кушылган кар бөртекләре узыша-узыша үзләренә урын сайладылар да, сукмакларга һәм юлларга түшәлеп яттылар. Мәктәптән кайтканда алдымдагы узып баручының эзләренә басарга уйлаган идем, юк, танытмады да, эзен дә күрсәтмәде. Өйгә кайтып җиткәч тә, ишек төбен көрәп кердем. Җил ишеккә кысылып калгандыр дисәм, моржадән кереп түрдә сызгырып йөри икән. Тәрәзәгә күз салыйм дигән идем, анда да буран кардан ак пәрдә корган иде. Бераздан басылгандыр инде дисәм, ул хәл җыеп кына посып торган. Киредән ачуланып-ачуланып карлар китереп өйде.

Ишегалларында, урамнарда йөрерлек калмады. Әтиләр тагын юллар ачтылар. Буран аларны үртәгән кебек, тиз арада көрәгән юлларын тагын томалап куйды. Ай дәвамында буран“җырын” урамнарда көрәк “җыры” алмаштырып торды. Кыш әллә безне эшсез тормасыннар, бераз хәрәкәтләнсеннәр дигәндерме, тик үз эшен күпкә арттырып үтәде. Хәзер без кар өстендәге сукмаклардан йөреп, күкләргә дә якынайдык. Йолдызлар да әрерәк күренә, Ай да якынрак кебек хәзер. Ул җирне тагын да яхшырак яктырта, аяз төнне урамнар яп-якты. Шулай итеп, быелгы кыш безне күп нәрсә белән бүләкләде. Яз җиткәч бу карлар дым булып җиргә сеңсәләр, җәйләр дә уңышлы килер дип уйлыйм.

***Зәйнәп Нурматова,Х сыйныф укучысы***